КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 22 июнь г.Казань № 733

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 30 декабрь, 1464 нче карары белән расланган 2023 елга Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең 2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең 2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлеген раслау турында» 2022 ел, 30 декабрь, 1464 нче карары белән расланган 2023 елга Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең 2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта:

14 пунктча үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле 25 пунктча өстәргә:

«25) «Авыл хуҗалыгы чималын эшкәртү биозаводын төзү» («Пектин» ҖЧҖ, Чүпрәле муниципаль районы).»;

1.13 пунктта:

20 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20) «Зеленодольск шәһәрендә урнашкан азык-төлек һәм азык-төлек булмаган товарларның универсаль склады» («Зеленодольск 3 күпләп бүлү үзәге» ҖЧҖ, Зеленодольск шәһәре );»;

түбәндәге эчтәлекле 31 – 34 пунктчалар өстәргә:

«31) «Мастер» Кама сәнәгать технопаркын төзү («Мастер» Кама индустриаль паркы» АҖ, Яр Чаллы шәһәре);

32) «Олимп» сәнәгать технопаркын төзү («Мастер» Кама индустриаль паркы» АҖ, Яр Чаллы шәһәре);

33) «Промэнерго» сәнәгать технопаркын үстерү (3 нче чират)» («Искра-Волга» ҖЧҖ идарәче компаниясе, Зеленодольск муниципаль районы);

34) «Әлмәт» индустриаль аграр паркын төзү («ТАКПО» ҖЧҖ, Әлмәт муниципаль районы).».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин